
Әдхәт Синугыл

# Ник елыйсың, курчагым?





Әдхәт Синугыл

# НИК ЕЛЫЙСЫҢ, КУРЧАГЫМ?



Казан
Татарстан китап нәшрияты
2000

# Курчак елый

Уяндым мин бүген
Бик иртән.
Күрәм: курчак елый...
Ник икән?

— Матур апам, кулым
Сынды,— ди...
Ялгап куйсаң иде
Шуны,— ди.
Елама син юкка,
Елама.
Җилем сылыйм хәзер
Мин аңа!
...Җилем сөрткәч, кул тиз
Ялганды.
Курчагымның хәле
Җайланды!





# Укыйсым бар!

Эше бик күп әнинең,
Бер эше юк бәбинең...
Юкка елый да елый,
Елап җиңәргә уйлый.

Бәби, нигә елыйсың,
Нигә йоклыйм димисең?
Әллә шуны белмисең —
Укыйсым бар ич минем!

# Минем энем

Мин чигәм күбәләк
Өр-яңа күлмәккә,
Энемә бүләккә.
Энемнең күлмәге
Зур түгел, кечкенә,
Тап-таман өстенә.
Ә энем бишектә
Талпына, тирбәлә,
Үсәргә өйрәнә...






# Зоопаркта

Зоопаркка баргач мин
Җәнлекләрне җәлләдем.
Сез дә, дуслар, аларның
Аңлыйсыздыр хәлләрен.

Җәнлекләр бит барсы да
Утыралар читлектә.
Нинди яхшы булыр иде
Йөрсә алар иректә.





# Кырын ятып

Физкультура дәресеннән
Кача-поса кайтып:
— Шырпы керде табанга,— дип,
Хәйлә таба Хатип.
Өйдә берәр эш кушсалар,
Күз дә йоммый Хатип:
— Өйгә күп эш бирделәр,— ди,
Күн диванга ятып.
Җәй көне дә эш эшләргә
Уйламый да Хатип:
— Яңа уку елына мин
Көч җыям,— ди,— ятып!



# Чөгендер

Чөгендер, әй, чөгендер,
Син яраткан сыемдыр,
Чия кебек төсләрең,
Бизи өстәл өсләрен.
Телем-телем түгәрәк,
Куям сине телгәләп,
Өстәлебез түрдәрәк,
Сыйланабыз бергәләп.





# Уңган Кояш

Кыздырыпмы кыздыра,
Кояш барын уздыра.
Иртә тора, соң ята,
Безне таңнан уята...
Барын да ул үстерә,
Җиргә нурлы төс керә.
Җирдә барын җылыта,
Туңган икән, җебетә.
Җиләк-җимеш пешерә,
Хезмәт итә кешегә.

# Кар ява

Бөтерелеп, бөтерелеп
Мамык карлар оча гына.
Очып-очып арыгачтын,
Ята җирнең кочагына.

Шаян карлар, наян карлар
Һәммәбезне сөендерә,
Тирә-якта бөтен җирне
Ап-ак туннан киендерә!

# Кар бабай

Җирнең өстен акка төреп,
Ап-ак җепшек кар ява.
Бергәләшеп без Кар бабай
Ясап куйдык бакчада.

Кар бабабыз шактый гына
Матур чыкты, ярыйсы.
Кулына көрәк тоттырдык,
Кар көрәргә анысы.





# Буран

Буран котыра,
Карлар очыра,
Бөтен дөньяны
Көрткә тутыра.
Ялыктым инде
Өйдә утырып...
Ял итим әле —
Кар көрим чыгып!

# Эчтәлек

Курчак елый . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 2
Укыйсым бар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 4
Минем энем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 4
Зоопаркта . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 6
Кырын ятып . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
Чөгендер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
Уңган Кояш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
Кар ява . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Кар бабай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Буран . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11



ББК 84 (2Рос=Тат)-5
С 45

Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен

*Юлия Щетинкина* рәсемнәре

Издание для детей и юношества

***Адхат Синугыл***

**Синегулов Адхат Макаримович**

# Не плачь, кукла

Стихи

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире *Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Копьютерда биткә салучы *Н.П.Клипова*
Корректоры *Г.Г.Зиннәтуллина*

Нәшриятка 0201 нче номерлы лицензия 1997 елның 22 августында бирелгән.

Басарга кул куелды 22.09.2000. Форматы 60×90 1/8. Офсет кәгазе № 1. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма. Басма табагы 1,5. Шартлы буяу-оттиск 8,0. Нәшер-хисап табагы 2.41. Тиражы 5000 данә. Заказ № К-2335.

Татарстан китап нәшрияты. 420503. Казан, Бауман ур. 19.
Татарское книжное издательство. 420503. Казань, ул. Баумана, 19.
http://www.tatarstan.ru/books/
e-mail: tki@books.kazan.ru

Отпечатано с готовых диапозитивов в РГУП ИПК «Чувашия»
428019. Чебоксары, пр-кт И.Я.Яковлева, д.13.

ISBN 5-298-01014-8

© Татарстан китап нәшрияты, 2000

